| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 г.Лениногорск № 1150

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 6 июлендәге номерлы карары белән расланган Җирлек территориясе өстеннән авиация эшләре башкаруга, парашюттан сикерүләр, һава судноларының күрсәтмә очышлары, тагылма аэростатларны күтәрү, пилотсыз һава суднолары очышларына (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан кимрәк булган пилотсыз һава судноларын очышларыннан тыш), шулай ук Лениногорск муниципаль районы территориясе өстендә аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган торак пункт чикләрендә урнашкан мәйданчыкка утыру (очып китү) эшләре башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 6 июлендәге номерлы карары белән расланган Җирлек территориясе өстеннән авиация эшләре башкаруга, парашюттан сикерүләр, һава судноларының күрсәтмә очышлары, тагылма аэростатларны күтәрү, пилотсыз һава судноларын

очышларына (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан кимрәк булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш), шулай ук Лениногорск муниципаль районы территориясе өстендә аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган торак пункт чикләрендә урнашкан мәйданчыкка утыру (очып китү) эшләре башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма запросын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан запросның электрон формасының кырлары дөрес тутырылмавы ачыкланган очракта гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры электрон запрос формасында мәгълүмати хәбәр ярдәмендә бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар карау өчен уңайлы булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-17-41